Актаныш муниципаль районы Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе

# Әдәби әсәрләрдә бюрократиянең гәүдәләнеше

*8 класста Ш.Камал һәм Ф.Садриев иҗатларын чагыштырып өйрәнүгә багышланган мастер-класс*



югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Салахов Рамил Җәмигънур улы

2015 ел

**Тема.** Әдәби әсәрләрдә бюрократиянең гәүдәләнеше.

**Максат.**

- Укучыларны уйларга өйрәтү, мөстәкыйльлек, үзаң формалаштыру;
- Илебез язмышында бюрократиянең тискәре роль уйнавын күрсәтү;
- Ш.Камал һәм Ф.Садриев әсәрләрен чагыштыру нәтиҗәсендә бәхетнең кешенең үз эш-гамәлләреннән торуына төшендерү.

**Өйрәнелә торган әсәрләр**. Ш.Камалның “Матур туганда”романы, Ф.Садриевның “Бәхетсезләр бәхете” романы.

**Дәрес төре.** Мөстәкыйль эш.

Укучылар 4әрләп төркемнәргә бүленгән. Төркемдәге укучыларга 1; 2; 3; 4 дип саннар беркетелгән. Бер җавап биргәндә һәр төркемнән 1 нче номерлылары, икенче җавап биргәндә 2 нче номерлылары төркем өчен җавап бирә.

Кабинетның бер ягына Ш.Камал портреты эленгән, икенче ягына Ф.Садриев портреты. –Укучылар, карагыз әле, бу кем портретлары? Кайсысы сезгә якынрак кебек, шул портрет янына килергә. (Конэрс структурасы) 2 минут вакыт- ни өчен бу язучы сезгә якынрак? (таймд-пэа-шэа)

*-Татар әдәбияты классигы Ш.Камалның кыска хикәя жанрын үстерүгә керткән өлеше аеруча зур. Әсәрләренә тирән психологизм, эмоциональ-лирик моң, мәгънәви тирәнлек, композицион җыйнаклык хас һ.б.*

*-Якташ язучы-прозаик һәм драматург Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев Әлмәт Язучылар берлегенең Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләгенә, Р.Фәхретдинов исемендәге премиягә, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе. Мөслим районының Мактаулы гражданины. Әсәрләре тормышчан эчтәлекләре, үзенчәлекле кеше образлары, халыкчан юморга бай йөгерек тел-стиле белән җәлеп итәләр, һ.б.*

-Ә хәзер игътибар тактага. (Бюрократиягә багышланган фотослайдлар)

-Укучылар, нәрсәләр күрдегез?

- *Җитәкчеләрнең идарә итүе. Бюрократия, берсе өстеннән икенче кеше, аның өстеннән өченчесе һәм шулай дәвам итә торган чылбыр.*

-Дөрес. Ә кемнәр соң ул бюрократлар? Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә мондый аңлатма бирелгән.

**БЮРОКРАТ**. 1. Буржуаз дәүләтләрдә: бюрократик идарә системасындагы зур дәрәҗәле түрә. *Дума таратылгач, бюрократлар куәт алды, Хөррият тарафларны төрмәгә салды.*Ш.Мөхәммәдиев.

2. Төп игътибарны эшнең формаль ягына биреп, эшнең асылына зарар китерүче хезмәткәр (гадәттә җитәкче). *Үзе чакырган булды. Үзе тагын урынында юк.* Г.Иделле.

**БЮРОКРАТИЯ.** 1. Буржуаз дәүләтләрдә идарә итү системасы: халыктан аерылган һәм хаким сыйныф файдасына эшләүче түрәләрдән торган идарә аппараты. *Бюрократия үзенең эшләрен халыкка белгертәсе килми.* Урал.

2. Төп игътибарны эшнең асылына, эчтәлегенә бирмичә, рәсми-формаль ягына (инструкцияләргә, күрсәтмәләргә туры килүенә, тиешенчә язып теркәлүенә, документлаштырылуына һ.б.) юнәлтеп идарә итү системасы.

- Ә әле яңарак кына безнең ике төркемгә бүленүебезгә сәбәпче булган язучылар белән бу слайдта күргән сурәтләр, ягъни бюрократлар ничек бәйләнә?

- *Бу язучыларның без укыган әсәрләрендә (Ш.Камал. Матур туганда. Ф.Садриев. Бәхетсезләр бәхете.) үзләре өчен генә яшәүче, бары үзләрен генә кайгыртып, гади халыктан ераклашкан җитәкчеләр сурәтләнә.*

- Безнең бүгенге дәреснең темасы нинди булыр инде, укучылар?

- *Ш.Камалның “Матур туганда” һәм Ф.Садриевның “Бәхетсезләр бәхете” романнарында бюрократиянең гәүдәләнеше.*

-Бик яхшы, узган дәрестә Ш.Камалның “Матур туганда” романында бер-берсенә каршылыкка килгән ике сюжет сызыгы булуы турында сөйләшкән идек. Берсе аның- матурлык- коммунарларның тырыш хезмәте, яшәеше, табигать матурлыгы, элгәреге хуҗалар төзегән шәһәр советы бинасы төзелеше һ.б. Икенчесе- ямьсезлек. Ә хәзер, кадерле укучылар, әйдәгез әсәрдән ямьсезлек сурәтләнгән урыннарны санийк әле.

- *Һидият белән Мостафаны, кызу урак өстендә эштән аерып, комитетка чакырулары; очрашу вакыты билгеләнгән булса да, Сәмигуллин янына керә алмый көтеп утырулары; техник секретарь Гыйльмановның үзен дорфа тотуы, мыскыл итүе; балык тоту вакыйгалары.*

- Бик яхшы, укучылар, балык чиерттерү вакыйгасын Ш.Камал тәмләп, күп итеп яза. Бу хакта ул кабат-кабат сөйли. Нинди нәтиҗәгә киләбез?

-*Эләкмәгән балык чиртүенә шатланып, шуңа канәгать булып утыруны юк эш белән шөгыльләнү дип әйтә алабыз. Фәтхинең Мәдинәгә өйләнимме дигән соравына Сәмигуллин өйләнмәскә куша. Төп сәбәп итеп, инде бюро әгъзасы булып күтәрелгән Фәтхигә ярарлык тәмле аш пешерә алуына шикләнә. Тәмле итеп пешерелгән аш бу кешеләр өчен мәхәббәттән дә, кешеләр язмышыннан да кадерлерәк булып чыга. Алар үзләреннән түбәнрәк торган кешеләр турында уйлап та карамыйлар. Башка кешеләрне кармакка эләктерә торган вак балыкка тиңлиләр.*

- Фәтхинең Мәдинәгә өйләнергә исәбе бармы? “Юк”,- ди Ш.Камал. Фәтхи Мәдинәгә моннан соң да хатлар язачак, бүләкләр җибәреп, кызны өметләндерәчәк, ләкин өйләнергә кыюлыгы җитмәячәк. Ниһаять, уңган, чибәр, яхшы күңелле Мәдинә, аңа кул селтәп, Әндәрҗан исемле үзе кебек әйбәт кешегә кияүгә чыгачак. Ә Фәтхи? Ул егет чагындагы кебек башын кашып калачак. Аннан соң үкенеп йөриячәк. Шәриф Камал Мәдинә белән Фәтхи язмышын “Матур туганда” романының дәвамы булган “Ныклы адымнар” романында шулай яза.

-Фәтхи белән Сәмигуллин кебекләр төзегән яңа тормыш нинди була ала? Ш.Камал бу сорауга ачык җавап бирми. Хәер, җавабы булса да, ул заманда әйтә алмас иде.

-*Яңа тормыш гади халык өчен төзелми. Түрәләр ни тели, шуны эшли ала торган җәмгыять барлыкка килергә мөмкин.*

---

-Ә хәзер мин сезнең игътибарыгызны якташ язучыбыз Ф.Садриевның “Бәхетсезләр бәхете” романына юнәлдерер идем. Шәриф Камал әсәрендә әле артельләр, коммуналар төзелә башлаган дәверне бәян иткән. Ф.Садриев кайсы чорны сурәтли?

- *Илдәге 90 нчы еллардагы авыр вәзгыять башлану чоры; язучы әйтмешли, черек нигезле партиянең җимерелү чорын сурәтли.*

-Әсәрдә сүз нәрсә турында бара? Кыскача гына сюжетын сөйләп китсәк иде.

- *Яшь, сәләтле, энергияле Ирек Сабитовның КПСС сафларына алынып, идеология бүлегендә инструктор; район газетасында редактор; соңыннан музей җитәкчесе булып хезмәт итүе турында. Аның бик күп сынауларга дучар булып, кырыс шартларда да үзе булып калуы турында.*

-30 нчы ел бюрократлары белән чагыштырып, 90 нчы елгылары турында нәрсәләр әйтер идегез?

- *90 нчы елгы түрәләр, болганчыклыклардан файдаланып, ил байлыган үзләштерә. Алар өчен кешелеклелек, дуслык кебек сыйфатлар ят. Барысы да хәйләкәр, азгын. Үз дигәннәренә ирешү өчен барлык ысулларны да үтәргә әзер. Ләкин карьера ахыры барысыныкы да бертөрле аяныч тәмамлана. Алар үз язмышлары турында уйлый башлыйлар. Упкынга килеп терәлүнең сәбәпләрен, ялгышлыкның кайда җибәрелүен эзлиләр.*

**Физкультминут**. Микс-пэа-шэа структурасы. Татарча бию көе куела. Бию барышында сорау бирелә, җавaптагы сан буенча төркемдәге укучылар парланалар.
- “Бәхетсезләр бәхете” әсәрендә пратия оешмасының ничә беренче секретаре, ягъни район башлыгы язмышы сурәтләнә. (Җавап 2. Арсланов Миңзаһит Усманович, Шәрифуллин Әхнәф Хәсәнович)
- “Матур туганда” әсәрендә Мәдинәнең ничә баласы бар? (Җавап 1. Ире Нуретдин Сабитов яраланып 2 атна лазаретта ятканнан соң, Мәдинәне сигез яшьлек бала белән тол калдырып үлә.)
-“Бәхетсезләр бәхете” әсәрендә карт коммунист Сабитов Хәйринең ничә улы бар? (Җавап 2. Мэлс һәм Ирек Сабитовлар)
- “Матур туганда” әсәрендә бандитлар белән канлы көрәш нәтиҗәсендә коммунарлардан ничә кеше үтерелде? (Җавап 2. Каюм, Ишмай картның улы комсомолец Мәхмүт.)
-“Матур туганда” әсәрендә Садыйк бай каравылчы Галләметдингә ничә баш сыер вәгъдә итә? (Җавап 1. Холмогор токымлы 1 баш нәселле сыер)

- Укучылар, җитәкче булып тумыйлар. Аларны халык сайлый, алар халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы кешеләр бит инде. Ә ни өчен алар, мәсәлән, “Бәхетсезләр бәхете” әсәрендә элекке беренче секретарь Миңзаһит, аның урынына район башлыгы булып күтәрелгән Шәрифуллин Әхнәф халыктан ераклашты соң? Алар үкенәме?
-Бик яхшы, укучылар. Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек? (Җаваплар тыңлана, өстәлә, тулылындырыла).
-Мин бу дәреснең эпиграфы итеп Ирек Сабитовның сүзләрен китерер идем. “Һәр кеше берәү генә түгел, икәү. Икенчесе күктә йолдыз булып яна. Җирдән торып, шул күктәге үзең белән элемтә урнаштыра алсаң, син – бәхетле кеше”,- дип әйттерә үзенең төп героеннан Фоат Садриев. Бу- үз-үзеңә хыянәт итмәүнең бердәнбер юлыдыр. Күктәге йолдыз җирдәге шакшылыклардан һәрчак өстен кала. Корымлы казан янында ак киемнәрдән йөреп, без ак калалмыйбыз. Шул чакларда икенче үзең булып калу өчен күктәге йолдызыңа омтылырга кирәк. Ә “Бәхетсезләр бәхете” әсәрендәге түрәләр моны соңрак аңладылар; упкын янына килеп терәлгәч кенә, хакыйкать эзләргә тотындылар.
-Бу ике әсәрнең охшаш һәм аермалы яклары турында нәрсә әйтерсез?
- *Икесендә дә үзләренең мәнфәгатьләрен өстен куеп, гади халыктан ераклашкан җитәкчеләр, бюро әгъзалары сурәтләнә. Җитәкче постка яңа гына сайланган гади халык вәкиле дә тиз арада “бюрократ авыруы” эләктерә. “Матур туганда” романында Фәтхи. Шулай ук Мостафа. Ул бик әйбәт кеше. Ләкин коммунада ячейка секретаре итеп сайлап куйгач, хәтта ул да, кешеләрчә сөйләшүен онытып, Сәмигуллиннар кебек сөйләшә башлый. “Бәхетсезләр бәхете” романында исә, Ирекнең дусты Әхнәф. Сайлауларда дуслары ярдәме белән җиңеп, хакимият башлыгы вазыйфасына күтәрелгәч, ул да дусларыннан аерыла. Үзгәрдегез дип, соңыннан дусларына үпкәләп йөри.*
*Ә аермасына килсәк, 1991-2005 нче елларда язылган “Бәхетсезләр бәхете” романын Ш.Камалның 1937 нче елда язылган “Матур туганда” романының дәвамы итеп тә карарга мөмкин. “Матур туганда” әсәрендә әле партия төзү еллары, күмәк хуҗалыклар барлыкка килү еллары сурәтләнсә; түрәләр матур тормыш барлыкка килү барышында ил үсеше өчен тоткарлык кына булсалар, “Бәхетсезләр бәхете” романында партия идеологиясенең җимерелүе; илебезнең болганчык вакыйгаларыннан файдаланып, түрәләрнең ил байлыгын үзләштерүләре турында бәян ителә.*
-Дәрескә йомгак ясап, төркемнәрдә синквейн төзибез.

| | |
|---|---|
| *-Бюрократия* | *-Бюрократия* |
| *Кырыс, караңгы* | *Томанлы, тирән тамырлы* |
| *Боза, югалта, артта калдыра* | *Бәхетсез итә, үзгәртә, кешелеклелекне бетерә* |
| *Күңелне бимазалап тора* | *Илнең чабуыннан тарта* |
| *Власть* | *Идарә итү ысулы* |

**-Өй эше.** “Бәхет” сүзенә синквейн төзергә.